Әдәби тел нормалары. Орфоэпик нормалар турында төшенчә. Сөйләмнең әйтелеш нормаларына нисбәтле бәяләү.

**Графика**

Графика һәм орфография. Татар алфавиты.

Рун язуы турында төшенчә. Гарәп язуы үрнәкләре белән таныштыру. Латин графикасы. Кириллица.Телнең орфографик нормалары.

**Морфемика (сүз төзелеше) һәм ясалышы**

Сүз төзелеше һәм ясалышы. Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Татар телендә сүз ясалыш ысуллары. Сүз төзелешендәге тарихи үзгәрешләр турында гомуми аңлатма. Этимологик анализ турында төшенчә.

Сүз төзелешенең төп сәнгати чаралары.

Сүзләрне сүз ясалышы һәм төзелеше ягыннан анализлау.

**Лексикология һәм фразеология.**

Сүз – телнең төп берәмлеге. Сүзнең лексик мәгънәсе. Төрки-татар сүзләре һәм алынма сүзләр. Татар теленең сүзлек составы.Нейтраль сүзләр һәм стилистик бизәкле сүзләр.

Лексиканың стилистик катламнары.Фразеологизмнарның сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре. Икетеллелек шартларында татар теленең лексик һәм фразеологик составы арту.

Татар теленең төп  лексик нормалары. Лексиканың төп сәнгати чаралары.Лексик анализ ясау.

**Морфология**

Сүз төркемнәренең лексик-грамматик төрләре. Сүз төркемнәренең классификациясе. Сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәте. Телнең төп морфологик нормалары. Морфологиянең төп сәнгати чаралары.

Морфологик анализ ясау.

**Синтаксис**

Синтаксис буенча гомуми мәгълүмат. Сүзтезмә һәм җөмлә. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше.Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләре. Гади җөмлә төрләре.

Кушма җөмлә турында төшенчә. Татар һәм рус телләрендә иярченле кушма җөмләнең төзелеше.

Текст синтаксисы турында гомуми төшенчә.Телнең төп синтаксик нормалары. Синтаксисның төп сәнгати чаралары.

Синтаксик анализ ясау.

**Сөйләм культурасы**

Язма тел һәм сөйләмә тел төшенчәләре. Әдәби сөйләмгә куелган таләпләр турында гомуми мәгълүмат. Сөйләмдә лексик чараларның (синонимнар, антонимнар, калькалар, фразеологизмнар, мәкаль һәм әйтемнәр) кулланылыш мөмкинлекләре.

Хәзерге матбугатта һәм электрон чараларда татар теленең кулланылыш үзенчәлекләре турында гомуми мәгълүмат.

**Пунктуация.**

Татар телендә тыныш билгеләре. Пунктуацион норма. Пунктуацион-мәгънәви кисәк.

**Тел һәм мәдәният**

Татар халкының теле,  мәдәнияте һәм тарихы арасындагы бәйләнеш. Татар сөйләм әдәбе. Аралашуның төренә бәйле сөйләм әдәбен куллану.

## УКЫТУНЫ МАТДИ-ТЕХНИКҺӘММӘГЪЛҮМАТИ ЯКТАН ТӘЭМИН ИТҮ

Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләрендә ана теле предметын укытуның матди-техник һәм мәгълүмати нигезенә түбәндәгеләр кирә:

- белем һәм тәрбия бирү өчен барлык шартлар да тудырылган, санитария һәм янгыннан саклану нормаларына туры килгән уку бинасы һәм мәктәп яны территориясе;
- ана теле предметын өйрәнү өчен җитәрлек күләмдә дәреслекләр һәм өстәмә методик ярдәмлекләр белән тәэмин ителгән китапханә;
- электрон китапханә, башка электрон ресурслар, татарча сайтлардан куллану мөмкинлеге булган компьютер классы;
- лингафон кабинеты;
- электрон һәм басма күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр;
- мультимедиа укыту программалары;
- компьютер программалары;
- 10-11 нче сыйныф укучыларының белемнәрен тикшерү программалары;
- төрле типтагы сүзлекләр, энциклопедияләр;
- белешмә материаллар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- интерактив тикшерү программалары;
- татар сайтлары (belem.ru; tatarile.org.com ).

**Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләрендәукучыларның ана(татар) теленнән белем, осталык һәм күнекмәләрен бәяләү нормалары(X-XI нче сыйныфлар)**

1. Уку күнекмәсен тикшерү һәм бәяләү:

10-11 нче сыйныфларда – 140 – 160 сүз.

2. Язма эшләрнең күләме һәм аны бәяләү: 4.

| Сыйныфлар | Контроль диктант | Изложение | Сочинение |
|---|---|---|---|
| 10 | 4 | 3 | 8 |
| 11 | 4 | 3 | 8 |

**Диктантларны бәяләү**

6. *Хатасыз* яки*бер* тупас булмаган хата җибәргән эшкә (орфографик, яки грамматик, пунктуацион) “5”ле билгесе куела.
7. 2 хатага “4” ле билгесе куела.

8. 5 хатага “3” ле билгесе куела.
9. 6 хатадан алып 12 хатага кадәр “2” ле куела.
10. 12 хатадан да артып китсә, “1” ле билгесе куела.

**Изложение һәм сочинениене бәяләү**

1. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле итеп ачылса; җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелсә; хаталар булмаса яки **1** хата (орфографик, грамматик, пунктуацион, стиль, фактик, логик) җибәрелсә, «5» ле куела.
2. Эчтәлек дөрес ачылып та, эзлеклелек сакланмаса, текстның башлам өлешендә төгәлсезлекләр китсә, 3 хата булса, «4» ле куела.
3. Текстның төп эчтәлеге бирелеп тә, эзлеклелек сакланмаса, текстның башлам һәм бетем өлешләрендә төгәлсезлекләр китсә, 5 хата (мәсәлән, бер орфографик, бер грамматик, бер пунктуацион, ике стиль хаталары) изложениедә, 6 хата сочинениедә җибәрелсә, «3» ле куела.
4. Эчтәлек дөрес һәм эзлекле ачылмаса, текстның күләме бик кечкенә булса, 12 хата китсә, «2» ле куела.

**Календарно-тематическое планирование по родному (татарскому) языку, 11 класс/**
**Туган (татар) телдән календарь-тематик план, 11сыйныф**

| № п/п | Тема урока/Дәрес темасы | Кол-во часов/ Сәг. саны | Дата | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| 1 | Язык –историческая ценность народа./Тел – милләтнең иң кыйммәтле тарихи ядкяре. | 1 | | |
| 2 | От ностративного языка до тюркских языков./Ностратик берлектән төрки телләргә кадәр. | 1 | | |
| 3 | Влияние языков друг на друга./Телләрнең үзара тәэсире. | 1 | | |
| 4 | Вводный контрольный диктант “Кто мы и откуда”/ Кереш контроль диктант “Без кем һәм кайдан?” | 1 | | |
| 5 | Работа над ошибками. Развитие речи. Сочинение: “Татарский язык. Прошлое. Настоящее. Будущее.”/ Хаталар өстендә эш. Бәйләнешле сөйләм үстерү. Телләрнең үзара тәэсире темасы буенча сочинение. «Татар теле: үткәне, бүгенгесе, киләчәге». | 1 | | |
| 6 | Тюрко-татарская этнонимика. Этнонимы древних тюрков./ Төрки-татар этнонимикасы Төркиләрдә иң борынгы этнонимнар | 1 | | |
| 7 | Регионы,где зарегистрированы древние тюркские этнонимы./Борынгы төрки этнонимнар теркәлгән регионнар. | 1 | | |
| 8 | Регистрация тюркских этнонимов как топонимов в Волго-Уральском регионе ./Төрки этнонимнарның Идел-Урал регионында топоним буларак теркәлеп калуы | 1 | | |
| 9 | Татар этнонимының этимологиясе һәм семантикасы. | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Этимология и семантика татарского этнонима./Татар теленнән программалар һәм дәреслекләр төзегән тел галимнәре | 1 | | |
| 11 | Ученые-языковеды, составившие программы и учебники по татарскому языку ./Татар теленнән программалар һәм дәреслекләр төзегән тел галимнәре | 1 | | |
| 12 | Фонетические, орфоэпические, орфографические, грамматические, стилистические, пунктуационные нормы татарского литературного языка./Татар әдәби теленең фонетик, орфоэпик, орфографик, грамматик, стилистик, пунктуацион нормалары | 1 | | |
| 13 | Фонетические, орфоэпические, орфографические, грамматические, стилистические, пунктуационные нормы татарского литературного языка./<br>Татар әдәби теленең фонетик, орфоэпик, орфографик, грамматик, стилистик, пунктуацион нормалары | 1 | | |
| 14 | Сочинение " татарская топонимика. Булгар-татарский, финно-угорский, Славянский слои в топонимике Поволжья Урала”./Сочинение “ Татар топонимикасы. Идел Урал топонимикасында болгар-татар, фин-угор, славян катламнары” | 1 | | |
| 15 | Работа над ошибками..Фонетические, орфоэпические, орфографические, грамматические, стилистические, пунктуационные нормы татарского литературного языка./Хаталар өстендә эш..Татар әдәби теленең фонетик, орфоэпик, орфографик, грамматик, стилистик, пунктуацион нормалары | 1 | | |
| 16 | Звук и фонема. Гласные и согласные звуки.Повторение порядка фонетического анализа./<br>Аваз һәм фонема. Сузык һәм тартык авазлар.<br>Фонетик анализ тәртибен кабатлау. | 1 | | |
| 17 | Словарный запас татарского литературного языка, словообразование и написание слов: корень,составные, парные, сокращенные слова./Татар әдәби теленең сүз байлыгы, сүзләрнең ясалышы һәм язылышы: тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә, кыскартылма сүзләр | 1 | | |
| 18 | Морфология. Написание (заявление, доверенность) делопроизводства по наименованию и его форме, роду, оформлению, порядку морфологического анализа./Морфология. Исем һәм аның килеш, тартым белән төрләнеше, ясалышы, морфологик анализ тәртибе Эш кәгазьләре язу (гариза, ышанычнамә). | 1 | | |
| 19 | Имя прилагательное, степени прилагательных. Сочинительная и подчинительная связь предложений. Послелоги./Сыйфат, дәрәҗәләре, ясалышы, морфологик яктан тикшерү Сүзләр һәм җөмләләр арасында ияртүле һәм тезүле бәйләнеш. Бәйлекләр. | 1 | | |
| 20 | Имя числительное, подгруппы, использование в предложении. Морфологический разбор./Сан, төркемчәләре, җөмләдә кулланылышы. Морфологик яктан тикшерү. | 1 | | |
| 21 | Наречие, его подгруппы, использование в предложении. Морфологический разбор./Рәвеш, аның төркемчәләре. Җөмләдә кулланылышы. Морфологик анализ ясау. | 1 | | |
| 22 | Местоимение, его подгруппы, использование в предложении. Морфологический разбор./<br>Алмашлык һәм аның төркемчәләре, ясалышы, җөмләдә кулланылышы. Морфологик анализ тәртибе. | 1 | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 23 | Развитие речи. Изложение “Родной язык”./Бәйләнешле сөйләм үстерү.“Туган тел” | 1 | | |
| 24 | Работа над ошибками. Глагол, его подгруппы, использование в предложении. Морфологический разбор./ Хаталар өстендә эш. Фигыль һәм аның төркемчәләре, җөмләдә кулланылышы, морфологик анализ тәртибе. | 1 | | |
| 25 | Синтаксис. Виды предложений с целью выражения: повествовательное, вопросительное, побудительное. Знаки препинания, интонация./Синтаксис. Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләре: хикәя, сорау, боерык, тойгылы җөмләләр, тыныш билгесе һәм интонация. | 1 | | |
| 26 | Синтаксис. Лексико-синтаксические упражнения. Синтаксический анализ./ Синтаксис. Лексик-синтаксик күнегүләр. Синтаксик анализ. | 1 | | |
| 27 | Контрольное изложение по теме "Синтаксис" (с элементами сочинения). "Акъаби"» / “Синтаксис” темасы буенча контроль изложение (сочинение элементлары белән). «Акъәби» | 1 | | |
| 28 | Работа над ошибками. Аналитические предложения и знаки препинания. Интонация и знаки препинания. / Хаталар өстендә эш. Аналитик иярченле кушма җөмләләр һәм алар янында тыныш билгеләре. Интонация һәм тыныш билгеләре. | 1 | | |
| 29 | Аналитические предложения и знаки препинания. Сочинение " Родная почва” /Аналитик иярченле кушма җөмләләр. Сочинение “Туган туфрак” | 1 | | |
| 30 | Работа над ошибками. Подготовка к диктанту./Хаталар өстендә эш. Диктантка әзерлек. | 1 | | |
| 31 | Промежуточная аттестация. Контрольный диктант “Первая охота”/Арадаш аттестация эше. Контроль диктант “***Беренче ау”*** | 1 | | |
| 32 | Работа над ошибками. Сочинение "Любимый писатель”/Хаталар өстендә эш. Сочинение. “Яраткан язучым” | 1 | | |
| 33 | Работа над ошибками. Сложные конструкции: многослойные и многослойные сложные предложения; средства, связывающие компоненты комбинированного предложения, знаки препинания./Хаталар өстендә эш. Катлаулы төзелмәләр: күп тезмәле һәм күп иярченле катлаулы кушма җөмләләр; катнаш кушма җөмлә компонентларын үзара бәйләүче чаралар, тыныш билгеләре. | 1 | | |

***Кереш диктант***

***Болытлар сәяхәте.***

Мин бакчада утырам. Күк йөзе чалт аяз. Бу җәйге көннәрдә ул юып куйгандай чип-чиста. Әнә ерак офык итәгеннән бер болыт йөзеп чыкты. Әкрен генә, тыныч кына килә. Күңелемне шатлык хисе биләп алды: болыт килә, болыт!

Күрәм, ул болыт мәһабәт ир кешегә охшаган иде. Күктә бик салкын, күрәсең. Әнә ул башына ак колакчын бүрек киеп куйган. Җилкәсендә бөдрә тун. Муенын кат-кат шарф белән ураган, һич шигем юк, бу — Әткә болыт.

Аның янәшәсендә генә тагын бер болыт. Бусы — Әнкә болыт. Зифа буйлы, чәчләре ташкын төсле дулкынланып тора. Менә озак та узмады, Әнкә болыт артыннан янә дә бер кечкенә генә болыт күренде. Ул әле рәтләп йөзә дә белми кебек. Як-якка авышкалап бара да аптырап туктап тора. Әлбәттә, бу – Бала болыт, дидем мин үз-үземә. Әйе, әйе, Бала болыт! Алар өчәү зәңгәр киңлек буйлап сәяхәт итәләр. *(Н.Дәүлидән)* (155 сүз)

***2.*** Итәгеннән, күңелемне, башына, колакчын, җилкәсендә, дулкынланып, өчәү ***сүзләрен тамыр һәм кушымчаларга аерыгыз.***

***3.*** Әнә ерак офык итәгеннән бер болыт йөзеп чыкты ***җөмләсендәге баш һәм иярчен кисәкләрне табыгыз, җөмлә кисәкләренә морфологик-синтаксик анализ ясагыз.***

***4.*** Җәйге, итәгеннән, бер, озак, алар ***сүзләренә морфологик анализ ясагыз.***

**Тест**

1.Татар теленең кайсы группага керүен билгеләгез. 1)флектив телләр группасына; 2)төрки телләр группасына; 3)фин-угор телләре группасына.

2. Татар теле белән кардәш булган телләрне күрсәтегез. 1)рус теле, немец теле; 2)инглиз теле, француз теле; 3)азәрбәйҗан теле, башкорт теле.

3. Татар теле белән кардәш булмаган телләрне билгеләгез. 1)испан теле, кытай теле; 2)төрек теле, казах теле; 3)үзбәк теле, башкорт теле.

4. Хаталы сүзне табыгыз. 1)сәгать; 2)сәнгәть; 3)солы.

5. Татар телендә тартык авазларның санын билгеләгез. 1)26; 2)27; 3)28.

6. Басым сүз ахырына куелмаган очракны күрсәтегез. 1)кайталар; 2)укып; 3)матур.

7. Күп мәгънәле сүзне билгеләгез. 1)тар; 2)тал; 3)төш.

8. Күчерелмә мәгънәле сүзне табыгыз. 1)җылы караш; 2)җылы бүлмә; 3)җылы көн.

9. Фразеологизмны күрсәтегез. 1)су йоту; 2)телен йоту; 3)ризыгын йоту.

10. Әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзләрне билгеләгез. 1)төнге, давыл; 2)җир, көчкә; 3)яхшы, чиста;

11. Әйтелеш белән язылышы туры килгән сүзләрне кусәтегез. 1)бау, тавык; 2)мәгърифәт, яулык; 3)бикле, исем.

12. *Төнге, бау* сүзләренә фонетик анализ ясагыз.

13. Фонетик принципка нигезләнеп язылган сүзне табыгыз. 1)борынгы; 2)чәчәкләр; 3)көнбатыш.
14. Морфологик принципка нигезләнеп язылган сүзне күрсәтегез. 1)чиксез; 2)әнкәй; 3)игеннәр.
15. График принцип белән язылган сүзне билгеләгез. 1)электр; 2)күлмәк; 3)урындык.

## *Изложение*

### *Татарстан нефте.*

Кешелек дөньясының гаҗәеп бер хасияте бар: инде ирешеләсенә ирешелде, тикшереләсе тикшерелде, шуннан ары булмас, дисең. Юк, каяндыр бер тынгы-сыз җан килеп чыга, әнә шул тынгысыз җан дөнья галимнәре белән пычакка пычак килә; үзенчә уйлап, үзенчә фикер йөртеп, үзенчә исәпли башлый. Карыйсың – булмастайны булдыра, адәм ышанмастайга ышандырып куя.

Гасырларга берничә генә туа торган әнә шундый тынгысыз җаннарның берсе – Иван Губкин.

Гаҗәеп кеше булган Михайло малае Иван. Ока елгасы буендагы Муром тирәсе авылларының берсендә туып, бала чагын көтү көтеп уздырган. Бөтеркәч башлы, каш астыннан карап йөри торган үсмер малай, сыерлары чирәм утлап йөргән чакларда, яр өсләреннән түбәнгә шуып төшә. Текә ярлар пычак белән телеп төшергән төсле! Җир кабыгы катлы-катлы. Бу бик тә сәер тоела малайга. Көзен, мал-туар абзарларга ябылгач, Иван мәктәпкә йөри. Зирәклеге, тырышлыгы белән танылып, укытучылар семинариясенә барып керә.

«Бу кеше үз юлын тапты инде, бөтен гомерен балалар укытып уздырыр инде», – дигәннәр авылдашлары. Авыл укытучысы ала торган унбиш сум жалованье сала мужигына буй җитмәс хәзинә булып тоелган. Ләкин Михайло малаеның күңелендә башка уй: актарасы иде тауларны, гизәсе иде дөньяларны!

Укытып алган акчасын ай саен яшерен янчыгына җыя барып, кирәк кадәр мая туплагач, хыялый егет аркасына юл капчыгы аса да Питер каласына юл тота. Анда реаль мәктәп буенча үзлегеннән имтихан тапшырып, Тау институтының мәрмәр баскычларына килеп баса.

Яһу! Бер урынга унар кеше туры килә торган имтиханга генерал балалары, купец-чиновник балалары җыелган чакта, кая инде ул мужик баласына анда борын төртү! Ләкин могҗиза: мужик баласы дигәнебез, белем байлыгы һәм кыю фикерләре белән имтихан алучыларны таң калдырып, институтка уза. Ярлы-ялчы хәлендә яшәп, ял көннәрендә Невада баржалар бушатып, җан-фәрманга тырыша торгач, китә эшләр җайга: сәламәт тәненә җегәр, зирәк башына белем җыйган Иван Михайлович Губкин, 1912 нче елның көзендә тау инженеры дигән беренче дәрәҗәле дипломны күкрәк кесәсенә салып, туп-туры Майкопка юнәлә.

Башлана шуннан тынгысыз эзләнүләр.

Көтүче-академик дип даны чыккан искиткеч зур галим нефть геологиясе буенча дөньяда иң яхшы дәреслекләрне яза. Икенче Баку районнарында – Иделдән алып Уралга хәтле булган гаять зур иңкүлектә – нефть эзли.

Дөньяга даны таралган укымышлылар бәхәсләшә Губкин белән. Ләкин көтүче-академик сүзендә нык тора. Аның кебек алдан күрү, аның кебек прогноз куя белү сәләте берәүдә дә булмый. Егерме еллык авыр хезмәт, егерме ел буена түгелгән маңгай тире бушка китми. 1932 нче елда безнең кардәш республикабыз Башкортстан туфрагында – Ишембайда сигез йөз метр тирәнлектән нефть фонтаны атып, агач буровойны күз ачып йомганчы йомычкага әйләндереп ташлый! Аннары Татарстан җирендә – Шандорлар, Нобельләр, Малакиенколар шөһрәт казана алмаган җирләрдә – Шөгердә, Баулыда, Писмән якларында бер-бер артлы нефть фонтаннары ата.

Әнә шул көннән башлап, иксез-чиксез Ватаныбызның барлык якларыннан олы хәзинә җирләренә илнең осталары җыела башлады. Алар арасында кайчандыр бәхет эзләп чыгып киткән татар эшчеләре дә бар иде. *(Г.Ахуновтан)* (455 сүз)

**Диктант**

**Туган җир**

Туган илне сагыну дигән хис тә төрле дәрәҗәдә, төрлечә була икән.

Менә син чит ил урамнарында ялгыз йөреп кара. Шагыйрь әйтмешли, син кем кадерлесе анда? Кинәт авырдың, ди. Докторга күренү өчен күпме доллар кирәк? Синең өчен анда беркем дә җавап бирми, син анда берәүгә дә кирәк түгел. Чит дөньяның иң эре башкаласында, иң зур урамның уртасында син-ком бөртеге,син-нуль.Ватан дигән газиз җирне әнә шунда син бөтен нечкәлеге белән аңлый башлыйсың. Мин бу хисне күп тапкырлар дөньяның күп калаларында кичердем.Бу хис бер җирдә минем күңелемнән китмәде.

Чын сагыну үзен шунда танытты.

Һәркемнең үз бала чагы, үз шәһәре, үз авылы, үз чишмәләре, үз таулары бар. Һәркем дөньяда безнең шәһәрдән, авылдан, чишмәдән, таудан матур урын юк дип ышанып яши бирә.

Җир шарында алты кыйтга бар, алар һәрберсе үзенчә матур. Әмма иң матуры-син туган, син үскән җир. ("Ватаным Татарстан" газетасыннан)

Х сыйныф

**Диктант**

Гомере буе кеше үзенең яшәү мәгънәсен аңларга, аның асылына төшенергә тырышты. Таптымы соң ул аны?! Монысын ул бүгенгәчә үзе дә белми әле. Ялгызы калып шул хакта еш уйланды ул. Хакыйкатьнең чын дөресен ача алу, аңлау үзе үк фәлсәфи тәгълимат бит! Һәм инде аны үз тормышында куллана белү күпләргә тәтемидер дә. Моның өчен синең рухың ирекле булу кирәк. Бу бәхет синдә юк икән, гомерең буе ул сине кол итеп тотарга мөмкин.

Кеше дөньяда үзенең табигый башлангычын табу, аны тормышка ашыру өчен күпме тырышты!.. Дуслары арасында үз-үзен таба алмаучылар, тормыш ритмыннан тайпылучылар да булмады түгел. Шуның нәтиҗәсендә үз йөзен, чынбарлыгын югалткан, үз-үзләрен алдап яшәүчеләр дә бихисап бит. Мондыйлар исә гомер бакый башкаларның рухи һәм матди байлыкларына кызыгып, хәтта көнләшеп яши бирәләр…

Кеше шулай әле бер якка, әле икенче якка авыша-авыша атлый бирә. Гомерендә байлыкка, дан-шөһрәткә кызыкмады, балаларын яхшылыкка өйрәтте. Тормышының күп өлеше үтелгән инде, хатирәләр артта калган. Җилкә бөкресе чыккан әлеге кеше, иңнәрендәге йөген күтәргән хәлдә, ничек туры атлап килә! Аны көр күңелле юлдашы – уе каршылый, җилкә бөкресенә кагылып хуплап куя. *(169 сүз.)*

*(Д.Гайнетдиновадан)*

***Тикшерү диктанты***

**Рәхмәт, Тормыш!**

Рәхмәт сиңа, кояш! Түп-түгәрәк булып тау артыннан көлә-көлә килеп чыкканың өчен. Көлүен бар дөньяга нур булып бөркелә. Сиңа үрелеп, гөлләр булып үсәбез, синдә наз, синдә яшәү, синдә шатлык.

Рәхмәт сиңа, җил! Ачык тәрәзәмнең челтәр пәрдәләрен җилфердәтеп, чәчләремә йомшак кагылып, күңелемне җилләндергәнең өчен. Рәхмәт,

җилкәй, бакчамдагы шомырт, сирень чәчәкләренең хуш исләрен миңа бүләк иткәнең өчен.

Рәхмәт сезгә, Туган җирем, болыннарым, тугайларым, кырларым! Рәхмәт сезгә, тәмле сулы чишмәләрем! Бер йотым суыгызда — мең дәва.

Рәхмәт, Тормыш! Сынауларыңа сынмаслык рухи көч биргәнең өчен. Матурлыкны күреп, яхшылыкны тоеп яшәү сәләтемнән аермавың очен. Кыенлыклар килгәндә, дулкын булып ярларга кагам, кош булып кыяга бәреләм, давыл булып шашам. Ә шулай да Кеше булып калу матуррак.

Рәхмәт, Тормыш! Кеше булып яшәвемне таләп иткәнең өчен. *(115 сүз.) (К. Шәфыйковадан)*

**Биремнәр.**

1.Тексттан ясалма сүзләрне табып, асларына сызарга.

2.*Болыннарым* сүзендәге сузык авазларга характеристика бирергә.

2. ***Изложение***

**Дуслык ничек туа?**

Зур панельле йортлар сала башлагач, ай-һай кызуга китте төзүчеләрнең эшләре. Печән кибәне хәтле экскаваторларның, яман уылдап, әреме-куагы, ташы-ние белән җирне умыртырга тотынуы була, машина-машина стена, йөге-йөге белән ишек-тәрәзәләр, идән-түшәмнәр китереп аударалар да, әкияттәге батыр шикелле, күз ачып йомганчы, биш-алты катлы йортларны утырталар да куялар, утырталар да куялар. Бер-бер аралы тезелеп кенә тора яңа урамнар. Көзен Камилләр Беренче Аркылы урамга күчеп килгәннәр иде. Хәзер андый урамнар җидәү. Тиз генә исем табып бетерүе дә читендер шул, барысына да Аркылы дип кушканнар.

Беренче Аркылы урамнан җиденче сыйныфта ике генә малай укый. Аларның берсе — Камил, түп-түгәрәк битле, кьсынкырак кара күзле, таза гәүдәле, авыр хәрәкәтле укучы, икенчесе — аның партадаш дусты Алик. Ул да гәүдәгә артык зур түгел, тик бөтерчек шикелле җитез, һәрвакыт каядыр ашыга, нәрсәгәдер омтыла, кызу-кызу сөйләшә, иптәше бер сүз әйткәнче, ул унны ычкындырып өлгерә. Озын керфекләр астына яшеренгән зур сөрмәле күзләре генә сабыр, уйчан һәм малайның хәрәкәтчән, җыйнак гәүдәсенә ничектер ят булып тоела. Камилләр дә, Аликлар да бу урамга бер үк көнне күчеп килделәр. Бер үк йортның бер катына да туры килделәр әле, җитмәсә. Ишекләре кара-каршы гына тора. Беренче көнне үк дуслаштылар алар.

Бишенче урам малайлары Камалләрнең авызына гына карап тора: соңрак килгәнгәдер инде, алар кыюсызрак әле, кунак шикелле, әдәпле тоталар үзләрен.

Шулай да озак бармады бу хәл. Кышкы каникулдан соң аларның сыйныфына тагын бер малай килде. Озын буйлы, киң җилкәле. Беләк һәм күкрәп мускуллары, гимнастеркасын тартып, тыгызланып тора. Килгән көнендә үк белделәр Камилләр: Фоат атлы бу малай җәен-кышын йөзү бассейнына йөри икән. Укучылар арасында йөзү буенча республика чемпионы да үзе.

Тышкы кыяфәте белән үк башкалардан аерылып торган Фоат, атна-ун көн дә үтмәде, сыйныфны үз кулына алды да бетерде. Хәер, Камил белән-Алик беренчелек өчен бәхәсләшергә уйлап та карамадылар. Чемпион хәтле чемпион белән дуслашу аларның үзләре өчен дә кызык иде.

Ә Фоат чыннан да шәп малай булып чыкты ул. Иң элек, Камил белән Алик шикелле терерәк малайларны җыеп, йөзүчеләр түгәрәге оештырды. Йөзүчеләр дип аны Фоат белән шул түгәрәккә йөргән малайлар гына чын күңелдән әйтә инде. Ә калганнары ачулары килгәндә, *я* үртәргә кирәк булганда шулай диләр. Чөнки Аликларның түгәрәккә йөри башлаганнан бирле бер тамчы да су күргәннәре юк әле. Физкультура залына алып керә дә

Фоат аларны, идәнгә яткырып, йөзү хәрәкәтләре ясарга өйрәтә, я җыелган саен гимнастика эшләтеп йөдәтә. Дөрес инде анысы, түгәрәк утырышлары шәһәрнең йөзү бассейнында үтсә, мең кат әйбәт булыр иде дә бит. Фоат әйтә: «Анда йөрүчеләр болай да бик күп, алдан өйрәнеп барсак, үзебез өчен яхшырак булыр»,— ди. Түзәләр инде Камилләр. Сыйныфташларының үртәүләренә дә, бертөрлелеге белән туйдырып бетергән гимнастика алымнарына да түзәләр. Аның каравы, язга чыккач, йөзү ярышлары башланып китсә, үртәп теңкәгә тиючеләр үзләре йөрерләр әле йөзүчеләр артыннан.

Тик бер ягы җитми Фоатның, грамматика белән дус түгел. Шулай да бирешергә чамасы юк малайның. Теше-тырнагы белән чытырдатып ябышкан ул дөрес язу кагыйдәләренә, тартышыпмы-тартыша. Үзенең генә көче җитмәгәч, иптәшләренең ярдәменә таянырга булды ул. (415 сүз)

*Л. Ихсановадан*

3. ***Фонетика темасына контроль диктант***

**Бөек шагыйрь авылында**

Бөек шагыйрь Габдулла Тукайның туган авылына мәхәббәте чиксез зур була. Бу авылның челтерәп аккан чишмәләре, яшел чирәмле урамнары, ерактан ук күренеп торган басу юллары — барысы да газиз, барысы да шагыйрь күңелендә тирән уелып калган. Шуның өчен ул аны сагынып искә ала:

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным, тәнем белән, — ди.

Менә без шагыйрьнең туган авылы Кушлавычта! Тукай әйткәнчә, авыл тау башына салынган. Төз һәм матур йортлары белән ул ерактан ук күңелне үзенә тартып тора. Элекке замандагы салам түбәле, төртсәң аварга торган иске өйләр урынында шулай мәһабәт булып калкып чыккан бу йортлар!

Авылның хезмәт сөюче кешеләре Тукайны тирән хөрмәт белән искә алалар. Алар үз колхозларын Тукай исеме белән атап йөртәләр, авыл китапханәсенә дә аның исемен биргәннәр.

Шул китапханә каршында гына сөекле шагыйребезнең һәйкәле бар.

Әсәрләре якты маяк булып балкыган шагыйребез менә шушы авылда туган, сабый чагында ук кимсетелүләр һәм ятимлекләрне дә шушы авылда кичергән.

Без дә Тукайны яратабыз, аның шигырьләрен кызыксынып укыйбыз. (172 сүз) *(С.Шакирдан)*

**Бирем.**

***Авыл, шагыйрь* сүзләренә фонетик анализ ясарга.**

**4. *Контроль изложение***

**Кызару**

Җәйге каникулны да бергә үткәрергә уйлап, мин Ногманны үзебезнең авылга алып китәргә булдым. Башта ул бераз уңайсызланып торса да, соңыннан риза булды. Зачетларны да уңышлы биреп тынычланып калгач, бик күтәренке күңел белән юлга чыктык. Без төшәсе станциягә килеп җиткәнче, андый-мондый нәрсә булмады. Вагоннан төшкәч тә, Ногманны багажлар янына утырттым да ат эзләргә киттем, чөнки безнең авылга барып

җитәргә егерме чакрымлап бар иде әле. Станциянең аргы ягына чыксам, бер ат әкрен генә юыртып китеп бара. Аны кычкырып туктаттым, янына бардым. Арбада ак яулыгын артка чөеп бәйләгән, кара күлмәк өстенә күк төстәге атланмалы алъяпкыч кигән бер хатын утыра. Карыйм — моның тут баскан битләрен, кап-кара күзләрен кайдадыр күреп калган кебек тоям. Кинәт исемә Ногманның акчасы югалган көнне безнең уртадан капчык күтәреп үтеп киткән хатын килеп төште. Нинди кызыклы очрашу. Аңа карап тукталып тормадым, аның кайсы авылга кайтуын сорадым. Аның юлы нәкъ безнең авыл аркылы үтәргә тиеш икән, ул безнең күрше авыл хатыны булып чыкты. Хатын безне утыртып алып кайтырга башта риза булмады. Атка правление рөхсәтеннән башка беркемне дә утыртып йөрергә хакы юклыгын әйтте. Ләкин, үтенеп сорагач, правлениегә барып, километр исәбеннән куелган бәядән хак түләү шарты белән генә утыртырга мөмкинлекне әйтте. Мин, акча түләү өчен күрше авылга барып йөрү кыенлыгын күз алдында тотып, акчаны аның үзенә генә тәкъдим итеп карадым. Ләкин ул бик кырку гына тавыш белән:

— Ничек инде ул, куелган тәртипне бозарга кушасызмыни, акча минем кесәдә калсын дисезмени? Мондый «яхшылык» өчен сезгә бик рәхмәт инде,— дип, мине нык кына кызартты.

Мин чемоданнарны арбаның бер як үрәчәсенә сөябрәк салдым да алар белән янәшәләп үзем дә утырдым.

Юл буенча Ногман бернәрсә дә сөйләшмәде. Мин генә, хатынның тормышына кагылырдай сораулар биргәләп, аның яшь кенә көе тол яшәвен, исеменең Фәрихә икәнлеген белеп алдым.

Бер урында тау менәсе булгач, без төшеп җәяүләдек, Фәрихә, ат тотучы булганлыктан, арбадан төшмәде. Көн бик эссе иде, Ногман кесәләрендәге барлык әйберләрен бушатып чалбар кесәсенә тутырды да өстен салып арбага илтеп куйды.

Тауны менеп җиткәч тә, икебез дә арбага менеп утырдык. Ат юырта башлагач, Ногман аякларын күтәреп арба читенә елышты. Фәрихә дилбегәне тарткан саен, ат, соры тузаннар туздырып, чапты да чапты.

Бераздан безнең авыл күренде.

Без авылга килеп җиттек.

Фәрихә, мин бик кыстасам да, чәй эчәргә дә кермәде, гадәттәгедән дә ныграк куа-куа, бик кызу китеп барды. Без өйгә кердек. Күрешү, ыгы-зыгы китте. Шул вакытта ике кулын да чалбар кесәләренә батырган Ногман кычкырып җибәрде:

- Слуши, Сәлим! Минем акча да, документлар да юк бит!

Өй эчендәгеләр дә, мин дә аптырап калдык. Бу ни хәл бу?

Чынлап та Ногман хаклы булды микәнни? Төрлечә уй йөртү, кычкырып сөйләшү китте. Мин: «Бәлки, чалбар кесәңнән арбага шуып төшеп калгандыр, табылмасмы әле»,— дип, Ногманны өметләндерергә тырышып карадым. Ногман миңа каты итеп җавап бирде:

- Бар, эт авызына кергән сөякне алып кара хәзер. Алырсың, табарсың!

Нәкъ шул вакытта ишек төбендә Фәрихә күренде. Кап-кара күзләрендә шелтә чагылдырып, Ногманга текәлде:

- Мәгез әйберләрегезне. Бигрәк каты әйтәсез икән. Алай таралып йөрергә ярамый. Әле яхшы, арба төбе тишек булмаган. Хушыгыз.

Ногман гүя телен йотты, хәтта «рәхмәт» дип тә әйтә алмады, аның битенә куе кызыллык йөгергән иде. (489 сүз)

5. ***Лексикология темасына диктант***

**Аналар һаман юксына.**

Хәтер... Ана тәрәзә янына баскан да тирән уйга чумган... Ул иң чиста, иң матур күлмәген кигән, башына бизәкле ак яулыгын бәйләгән, гәрәбә муенсасын таккан. Дивардагы сәгать вакытны саный. Алтмыш дүрт ел буена минутларны һәм сәгатьләрне барлый ул. Өстәлдә саргайган өчпочмаклы солдат хатлары ята. Диварда улының рәсеме эленеп тора. Ананың баласыннан шушы кадерле истәлекләр генә калган.

Хәсрәтле уйларга талган, хәтер диңгезендә йөзә ана. Улының фронтка киткәнен бүгенгедәй хәтерли ул.

Әнә, чаналы ат, урамны артта калдырып, каршыдагы сөзәк тауга менгән юлга чыкты. Егет ашыкмый гына чана артыннан атлый. Туктый да, авылына борылып, яңгыравыклы тавыш белән җырлап җибәрә: «Бу китүдән кайта алмасак, сау булыгыз, туганнар!» Ана бу җырны көн саен күңеленнән көйли.

Әйе, аналар күңеле беркайчан да картаймый. Ул, еллар үткән саен, һаман нечкәрә һәм сафлана гына бара. Аналарның хәтерләре дә кайнап типкән чишмә башы кебек. *(133 сүз.) (К. Тәхаветдиновтан)*

***Бирем.***

***1 вариант. Чиста, кебек, кадерле сүзләренең синонимнарын табып язарга.***

***2 вариант. Хәсрәтле, истәлекләр, ашыкмый сүзләренең синонимнарын табып язарга.***

**6. Йомгаклау арадаш аттестация эше (*диктант*)**

**Алиш белән очрашу**.

Тагын бераздан безнең түгәрәккә Язучылар берлегеннән ярдәмгә даими шеф та билгеләделәр. Бу кеше Абдулла Алиш иде. Бу вакытта мин, зурдан кубып, завод уйлап табучылары турында повесть язарга керештем. Алиш катнашкан утырышларның берсендә бу әсәремнән бер өзек укыдым. Хәзер аңлыйм: әлбәттә, ифрат шәфкатьле шефыбыз бу эшне мине дәртләндерү өчен эшләгәндер. Әмма шунысы хак: ул мине үтереп мактады. “Мин бу иптәш әсәрен укыганда ук кул чапмакчы идем, тик аны бүлдерәсем килмәде”,- диде. Аның шул сүзләреннән соң минем күңелем күкнең җиденче катына очты, һәм мин һәр буш вакытымны повестька багышладым. Абдулла Алишның кара хәтфәдәй күзләре, тыныч йөз-кыяфәте, икегә ачып таралган чәчләре – барысы да бүгенгедәй күз алдында. Урта буйлы, нык бәдәнле, матур кеше иде. Беркайчан да чыгарыннан чыкмас, һәрнәрсәне тулы һәм ачык итеп аңлатыр. Мин аның үзенчәлекле яңгыравык тавышын да ачык хәтерлим. (128 с.)

**Эшне бәяләү системасы**

Эш пөхтә башкарылса, хатасы булмаса «5» ле куела.(1-орфографик, 2 пунктуацион хата булырга мөмкин.)

2 орфографик, 2 пунктуацион яки 1 орфографик, 4 пункт. хаталы эшкә «4» ле куела.

4 орфографик, 4 пунктуацион яки 3 орфографик, 6 пункт. хаталы эшкә «3» ле куела.

6 орфографик, 5 пунктуацион яки 5 орфографик, 8 пунк. хаталы эшкә «2» ле куела.

Арадаш аттестация эше (тест)

1 вариант

1.Саннарны сүзләр белән языгыз

19, 25, 37, 56, 63, 74, 88, 96, 205,1892, 2009.

2. Җөмләләрне русчага тәрҗемә итегез

Унлап укучы яңа теманы яхшы үзләштерде. Кайбер укучыларга бер үк сүзне өчәр тапкыр әйтергә кирәк . Без татар төркемендә җидәү идек. Икенче Бөтендөнья татар корылтаенда җиде йөзләп делегат катнашты.

3.Җөмләләрне дәвам итегез

Ул бүген шундый күңелсез, шуңа күрә .... . Алар бик акыллы, ләкин ... . Дустым бик уйчан, әмма ... . Урамда бик салкын, шуңа күрә ... .

4. Кирәкле тартым кушымчаларын өстәп языгыз

Уку йорт... , укыту тәҗрибә... , рус һәм татар халык.. , Көнчыгыш ил... , татар әлифба... .

5. Сорауларга җавап бирегез

Сез нинди шәһәрдә яшисез? Син нинди урамда торасың? Россиянең нинди шәһәрләрендә булганың бар? Чит илгә чыкканың бармы?

6.Татарчага тәрҗемә итегез

В России проживают более 5 миллионов 500 тысяч татар. Более 1 миллиона татар живут за пределами России. Многие зарубежные татары знают язык своего народа. С 1981 года в Аделаиде работает татарская школа. Австралийские татары – учителя, врачи, банковские служащие, бизнесмены.

7.Фразеологизмнарны татарчага тәрҗемә итегез

Два сапога пара; обеими руками; меж двух огней; глаза на лоб полезли; рот до ушей.

2 вариант

1.Саннарны сүзләр белән языгыз

17, 23, 47, 58, 69, 72, 81, 99,103, 1997, 2008.

2. Җөмләләрне русчага тәрҗемә итегез

Һәр укучы унар сорау язарга тиеш. Ел саен Татарстан Призедентына йөзләрчә кешедән хатлар килә. Укучылар икешәрләп утыралар. Җәй көне Финляндиядә татар балалары 2-3 атнага лагерьга җыелалар.

3.Җөмләләрне дәвам итегез

Мин бүген шундый бәхетле, чөнки ...... . Яхшы эшләр генә эшләргә тырышсам да, ..... . Өлкән кешеләргә карата һәрвакыт ..... .Татар телен яхшы белергә теләсәң, .... .

4. Кирәкле тартым кушымчаларын өстәп языгыз

Россия илчелек..., Мәскәү университет..., татар теле укытучы..., татар язу..., Казан гимназия... .

5. Сорауларга җавап бирегез

Сез кайсы илдә яшисез? Син кайда укыйсың? Татарстанның нинди шәһәрләрендә булганың бар? Татарлар кайсы илләрдә яшиләр?

6.Татарчага тәрҗемә итегез

Более 80% татар проживают в Российской Федерации. Татары занимают по численности второе место. Татарские семьи общаются между собой, проводят национальный праздник Сабантуй. В Австралии большинство татар живет в городе Аделаиде. Здесь находится татарское общество.

7.Фразеологизмнарны татарчага тәрҗемә итегез

Делать из мухи слона; рот до ушей; в двух словах; как две капли воды; гнаться за двумя зайцами.